ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 4221776

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 3

КАРАР
от 31.01.2022г.

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Башкарма комитеты
к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. 3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче /И.П. Крешков/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2022 ел, 3 нче санлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3203,78 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 834,79 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2926,11 |
| **Барлыгы** | 6964,68 |

Җитәкче /И.П. Крешков/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы
Албай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2022 ел, 3 нче санлы
карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегендә күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 993,95 |
| 3.Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2300,80 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 851,70 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2818,23 |
| **Барлыгы** | 6964,68 |

Җитәкче /И.П. Крешков/